вә сәлләм: *«И, кешеләр! Бу дөньядан яшәп киткән кавемнәр тик шул сәбәптән һәлак булганнар: аларның зыялылары бернәрсә урласа, аны җибәргәннәр, зәгыйфьләре урлашса, аңа җәза биргәннәр. Аллаһы белән ант итәмен! Мондый эшне кызым Фатыйма эшләгән булса, һичшиксез, аның кулын да кистергән булыр идем»*, - дип әйткән. Безнең илдә дә шулай бит: бер сумлык әйбер урлаган гади кешене биш елга утыртып куялар. Берәр түрә вагоны белән миллионнар урласа, ирекккә җибәрәләр. Шуңа күрә дәүләтебездә бер-беребезгә ышану юк. Әгәр дә Раббыбыз Аллаһы хөкеме буенча безнең илебездә дә каракларның кулларын киссәләр, ул чагында бик күп кешеләрнең кулларын кисәргә туры килер иде. Кайберәүләр ислам дәүләтләрендә каракларга карата кулланылган шундый каты җәзаны аңламыйлар, гыйлемсезлекләре аркасында Аллаһы Тәгаләнең хөкеме һәм әмере белән килешәселәре килми. Янәсе караклык кылган кешенең кулын кисү урта гасырдан калган кыргый гадәт. Шулай дип, үзләренә җиңеллек эзләп, җаваплылыктан качып, акланмакчы булалар. Бүгенге көндә кемнәргә Аллаһы Тәгаләнең боерыклары караклык-угрылык кылырга комачаулык итә?! Әлбәттә, халыкны талау юлына баскан, караклык белән шөгыльләнгән кешеләргә.

Әгәр дә безнең илебездә дә, мөселман илендәге кебек, кеше әйберен урлаган өчен каракларның кулларын киссәләр, иманым камил, берәү дә кеше малына кагылмас, кеше әйберен урламас иде. Фатирларны басып йөрүче дә, машина ишекләрен җимереп талаучы да, бакчаларда күп хезмәт түгеп үстергән җиләк-җимешләрне урлаучы да, үлчәгәндә ким үлчәүче дә, сатканда бәясен тиешледән артык куючы да булмас иде. Бүгенге көндәге кебек күп санда полиция һәм мәхкәмә хезмәткәрләрен тотарга да кирәк булмас, төрмәләр дә бушап калыр иде. Төрмәдә бушка дәүләт җилкәсен күсе кебек кимереп ятучылар булмагач, салымнар да тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлтелер иде. Аллаһы Тәгалә чыгарган хөкемнәрне үтәп яшәүдән халыкка, дәүләткә күпме файда, чөнки Раббыбыз Аллаһы Үзенең хөкемнәрен хикмәт белән билгеләгән. Каракны төрмәгә утыртып кына урлашуларны киметеп булмый. Төрмәдән иреккә чыккач, ул кеше барыбер урлау кәсебенә тотыначак. Мөселманнар ни өчен урлашудан ерак торалар? Урлаган өчен кул киселүдән курку гына түгел, ә төп сәбәп - Аллаһы Тәгаләнең хәерле рәхмәтеннән мәхрүм калудан курку. АКШның Йель университеты психиатрлары (алар мөселман түгел), тикшерүләрдән соң, кул кисү куркынычы кешеләрне урлашудан туктата, дигән нәтиҗә чыгарганнар.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Кем үзенеке булмаган әйберне «минеке» дип дәгъва кыла, ул кеше бездән түгел, үзенә җәһәннәмдә урын хәзерләсен»,* - дип әйткән. Ягъни кеше әйберен үзләштерүче кеше мөселман түгел, ә җәһәннәмгә керергә хәзерләнүче булып чыга. Икенче бер хәдистә: *«Берәү урланганлыгын белә торып та, шул әйберне сатып алса, ул хурлыкка калуда һәм гөнаһлы булуда урлаучының тиңдәше булыр»,* - диелә.

Урлаучы да, урланганын белә торып, әйберне сатып алучы да җәһәннәм утына ризык булалар икән.

Бервакыт чүлдә яшәүче гарәпләргә инглиз илчесе килә. Үтеп барышлый бер өй алдында күп акча ятканын күрә, ә янәшәдә беркем дә булмый. Аптыраганнан йортка кереп хуҗага: «Сездә караклар юкмы әллә?» - дип сорау бирә. Йортның хуҗасы: «Юк, бездә каракларның кулларын кисәләр!» - ди. Илче: «Нинди кыргыйлык!» - дип гаҗәпләнә. Гарәп сорау бирә: «Дөресен генә әйтегез әле: сезнең илегездә көненә ничә кеше урлашкан өчен җавапка тартыла?» Илче: «Иң кимендә 50 кеше» - ди. Ә гарәп: «Ә бездә 40-50 елга бер мәртәбә генә бер каракның кулы киселде», - дип җавап бирә.

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә барчабызны да кеше малына кызыгудан, кеше малына кул сузудан сакласа, нәфесебезнең хуҗасы булып яшәргә насыйп әйләсә иде. Амин.

**Равил хәзрәт НУРУЛЛИН.**
**Яр Чаллының «Туфан» мәчете имам-хатыйбы.**
*(«Ислам нуры»)*

# Җомга көннәрендә

1. Ислам җомганы иң яхшы көн итеп исәпли. Бу көнне мәчетләрдә мөэмин-мөселманнар бергәләшеп җомга намазы укыйлар.

2. Җәмәгать белән җомга намазында катнашу – һәр мөселман кешесенең бурычы. Бары тик бу таләп балаларга, хатын-кызларга, физик мөмкинлеге чикле кешеләргә генә кагылмый.

3. Җомга намазына барыр алдыннан мөселман кешесе тәһарәт алырга яисә госел коенырга тиеш. Бу очракта госел коенуның камилрәк эш булып исәпләнүен дә искәртү кирәк.

4. Иң яхшы киемнәрне кию һәм ислемайлар сөртү (әгәр бу мөмкин булса) кирәк.

5. Авыз куышлыгын чиста тоту өчен мисвәк яисә теш щеткасы куллану мөһим. Җомга көнне мәчеткә бару алдыннан моңа аеруча нык игътибар итү сораладыр.

6. Намазга барыр алдыннан тырнакларны кисү һәм чистарту кирәк. Шулай ук киемнең чиста, сакал һәм мыекның пөхтә булуына да игътибар итү таләп ителә.

7. Әгәр дә берничә мәчеттә булу мөмкинлеге булса да (әгәр якын-тирәдә берничә мәчет булса), җомга намазын тулысынча бер генә мәчеттә уку хәерлерәк.

8. Мәчеткә мөмкин кадәр иртәрәк барырга тәкъдим ителә. Шулай ук мәчеткә җәяү бару хуплана.





күрмәгән һәр нәрсә шайтан вәсвәсәседер. Хак Тәгалә әйтә: *«Йә иман китергәннәр, әгәр бер фасикъ сезгә хәбәр китерсә, аны яхшылап тикшерегез, соңыннан үкенерлек булмасын»* (49:6). Рәсүлуллаһ әйтте: *«Мөэмин яман зан кылудан буш булмас, фәкать кальбенә яман зан килгәндә, аны яхшыга юраса, аннан котылыр».* Бел ки, гайбәт ул кешенең кальбендәге бер хастәлек вә аны дәвалау фарыз. Аның даруы ике төрле булыр. Беренчесе - гыйльми дару. Гыйльми дарулар да икегә бүленә. Беренчесе - гайбәт турындагы хәдисләрне өйрәнеп, һәр гайбәт сәбәпле үзеңнең савапларыңның гайбәте сөйләнгән күчерелүен исеңдә тоту. Рәсүлуллаһ әйтте: *«Гайбәт кешенең савапларын ут коры утынны яндырган кебек яндырыр».* Бәлки, синең гөнаһларыңнан күбрәк күпмедер савабың бардыр, гайбәт сөйләвең сәбәпле ул савап та юкка чыгар, һәм гөнаһларың күбрәк булып, син җәһәннәмгә төшәрсең. Гыйльми даруның икенчесе шундый: син бер гөнаһ эшләсәң, гозер эзли башлыйсың, ягъни аклана башлыйсың, башкаларның гөнаһларын белгәндә дә, аларны гозерле дип уйла, аларны саклый бел. Гайбәт сөйләүче үзен гаепсез, дип уйласа, шуны белсен, үләксә итен ашаудан да зуррак гөнаһ юк. Әгәр, дөрестән дә, гөнаһсыз булсаң, үзеңне киләчәктә дә гөнаһтан сакла һәм гайбәт сөйләү урынына Аллаһы Тәгаләгә зикер вә шөкер кыл. Гайбәттән котылуның икенче даруы: гайбәткә этәрүче сәбәпләрне контрольдә тоту. Беренче сәбәп: ачулану һәм үпкәләү сәбәпле гайбәт сөйләү. Бу очракта бер кешегә үпкәләү сәбәпле җәһәннәмгә төшүнең ахмаклык икәнен аңларга кирәк. Пәйгамбәребез әйтте: *«Үпкәсен җиңеп, ачуланган хәлдә сабыр иткән кешене Хак Тәгалә кыямәт көнендә чакырып алыр һәм җәннәтне һәм хуриләрне сайлап алырга боерыр».* Икенче сәбәп: башка кешеләргә ярарга тырышып, алар белән гайбәт сөйләшеп утыру. Моның даруы халыкка ярарга тырышып, Хакның газабына дучар булуның ахмаклыгын аңлау. Өченче сәбәп: үзенә бер гаеп якканда, ул гаепне башкага ягу. Мәсәлән, кайберәүләр: әгәр мин хәрәм ашасам, фәлән дә хәрәм ашый, диләр. Бу ахмаклыктыр. Чөнки бер кеше җәһәннәмгә төшәчәк икән, син дә аның артыннан керерсеңме? Берәрсе җәһәннәмгә төшерәчәк гамәл кылса, син дә аны кылырсыңмы? Дүртенче сәбәп: үзенең дәрәҗәсен күтәреп, масаеп йөрү өчен башкаларны сүгәр. Мәсәлән, ул кеше фикыһны белми, теге кеше рия өчен генә гыйбадәт кыла, дип сөйләр. Ә үзенең бу вакытта гайбәт сөйләгәнен аңламас. Әмма акыллы кешеләр аның гөнаһлы икәнен аңларлар, чөнки ул гайбәт сөйли бит. Әлбәттә, бу сүзләре белән наданнар каршысында ул дәрәҗә казаныр, ләкин Хак Тәгалә каршында түбәнгә төшәр. Бишенче сәбәп: бер кеше бай яки галим булуы сәбәпле аны халык хөрмәт итсә, башка берәү аның гаепләрен эзли башлый. Мондый кеше ике дөньяның да нигъмәтеннән мәхрүм калыр. Аның хөсете сәбәпле теге кешенең дәрәҗәсе кимемәс, бәлки, артыр гына. Тәкъдирдә язылган хөрмәт үзенең хуҗасыннан башка беркемгә дә насыйп булмас. Алтынчы сәбәп: берәү иптәшенең гөнаһ кылуына чын күңелдән кайгырып, аның гөнаһын башкаларга сөйләр. Ләкин бу барыбер гөнаһ. Кеше гөнаһы өчен кайгырып, үзең гөнаһ кылу да ахмаклык.

Гайбәтне җаиз кылган өч сәбәп бар: 1) залим солтанның золымы турында сөйләү; 2) бидгатьченең дингә керткән бидгате турында сөйләү; 3) ачыктан, яшермичә, гөнаһ эшләгән кеше турында сөйләү. Боларның гайбәтен сөйләү җаиз булуының сәбәбе шунда ки, болар гөнаһларын бөтен халык алдында яшермичә кылалар. Шуңа күрә алар гөнаһлары турында сөйләүчеләргә рәнҗемәсләр.

Гайбәтнең кәффарәте: тәүбә кылып, үкенү һәм гайбәт кылынган кешедән гафу үтенү. Болай эшләүче гайбәттән пакьләнер. Пәйгамбәребез әйтте: *«Бер кешенең күңеленә яки малына золым итүче, савапларын бирәчәк көн килгәнче ул кешедән гафу үтенсен».* Әгәр дә гайбәте сөйләнелгән кеше үлгән булса, аның өчен истигъфар кылырга кирәк. Пәйгамбәребез әйтте: *«Бер кеше башка берәүнең гайбәтен сөйләсә, аның өчен Аллаһы Тәгаләдән мәгъфирәт сорасын».* Әмма тере кешеләрнең янына барып, алардан гафу үтенергә кирәк. Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез әйткән: *«Гайшә анабыз бер хатынның теле озын дигәч, Рәсүлуллаһ әйтә: «Гайшә, гайбәт кылдың, ул хатыннан гафу үтен, дигән».* Әгәр дә гайбәт ителгән кеше сине гафу итмәсә дә, бу аның хакы, син аны барыбер хөрмәт ит. Бу хөрмәтең өчен бирелгән савап кыямәт көнендә гайбәтең өчен теге кешегә бирелер. Ләкин гайбәт ителгән кеше, кыямәткә калдырмыйча, бу дөньяда ук үзеннән гафу үтенүчеләрне гафу итсә, аңа кыяметтә тагын да күбрәк савап бирелер. Хәсән әл-Басриның берәү гайбәтен сөйләгәч, ул теге кешегә бер табак хөрмә бүләк итә һәм: «Син миңа гыйбадәтеңне бүләк иттең, мин дә сиңа азрак булса да бүләк бирәм, кабул ит, зинһар, синең кебек үк зур бүләк бирмәсәм дә», – ди.

**(Ахыры бар)**




**- “Йәсин”, “Тәбәрәк”нең татарча мәгънәсен укырга ярый, дигәнне ишеткәнем бар. Шул дөресме икән?**

- Сүрәләрнең татарча мәгънәсен укырга ярый, ләкин савап булмый. Бу бары тик гыйбрәт өчен генә эшләнә. Әлеге дә баягы вәгазьгә керә ул. Савап булсын өчен бу сүрәләрне гарәп телендә укырга кирәк. Гарәп хәрефләрен белмәсәң, кириллицада транскрипциясен укырга мөмкин.

**- Иртәнге, икенде намазлары артыннан нәфел намазлар укыламы (тәүбә, тәһарәт намазлары һәм башкалар)?**

- Иртәнге намаздан соң кояш чыкканчы, икенде намазыннан соң кояш батканчы, нәфел, мәчет намазларын укырга ярамый. Иртәнге намазны укып, кояш чыккач, икенде намазын укып, кояш баткач, нәфел намазларны, мәчет намазларын укырга ярый.

*(“Дин вә йола” газетасыннан)*